
ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ФЕВРАЛЬ * 2021 * КАЗАН

2



Сергей АНДРИАНОВ

Рашат **НИЗАМИ**

ШИГЪРИ ШАРЖЛАР

* * *

Николай Карамзинга

Әй син, Кара морза! Тарих яздың –
Урысларның данын якладың.
Кирпеч калынлыгы хезмәтеңдә
Ник татарга урын тапмадың?..

* * *

Рудольф Нуриевка

Париж дигән табутында
Ята татар баласы.
Ул – Парижның горурлыгы,
Милләтемнең ярасы...

* * *

Нәкый Исәнбәткә

Зиһен ягын Ходай биргән,
Гыйлем ягын – мәдрәсә.
Берүзеңдә әллә ничә
Институт ләбаса!

* * *

Ренат Харискa

Кай арада язып өлгерә ул
Поэмалар, яңа либретто?
Шешәсеннән гүя чыгарганнар
"Шигъри җен" дигән гыйфритне!

* * *

Данил Салиховка

Әйдәклисең каләм ияләрен,
Гади телдә әйтсәк – көтүче.
Әдипләрне житәкләгән өчен
Берәүгә дә әле
Булмагандыр рәхмәт әйтүче...

* * *

Рәшит Зәкиевкә

Ялга чыктың. Ә каләмең әнә
Уйламый да ялга чыгуны.
Темаларны каян "эләктерәсең" –
Әйтеп бирче безгә син шуны!

* * *

Ринат Абзаловка

Тормыштагы ямьсез күренешләр
Килеп төртеләдер бәгырьгә, –
Кайчагында, пумаласын ташлап,
Сатирага күчә, шигырьгә!

* * *

Алмаз Хәмзингә

Шигырь яза, көйләр-җырлар яза
Һәм баянда уйный сыздырып.
Сәхнәләргә менсә – моң тарата
Чытлык җырчыларны уздырып!



Василий **АЛЕКСАНДРОВ**

ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Бу каһәр суккан коронавирус турында уйланам да, төрле күңелсез фикерләр башка килә. Бу афәтне санаулы секундлар эчендә эләктереп, әллә никадәр хастаханәдә аунап ятарга була. Ә менә сәламәт булып калыр өчен, начар гадәтәтләрдән баш тартып, спорт белән шөгыльләнеп, чыныгып, дөрес тукланып иммунитетны ныгытырга кирәк. Монда ниндидер гаделсезлек бар, минемчә...

Р. ВӘЛИЕВА

әлмәт

– Безнең укучыбыз мең кат хаклы, – диде Шомбай ага. – **Авыруны йоктырып була, ә сәламәтлекне йоктырып булмау – коточкыч гаделсезлек...**

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Хөкүмәт беркайчан да бернәрсәгә дә өйрәнми. Аның каравы, халык өйрәнә.

Ирекле дәүләттә һәркемнең күккә үз юлы белән китәргә хокукы бар.

Мактаулы исемнәр – ахмаклар өчен; бөекләргә үз исемнәре дә җитә.

Аңламыйм: хөкүмәтне нәрсә өчен сүгәләр? Ул берни дә эшләми бит.

Уйламыйча яшәр өчен бик күп ысуллар уйлап чыгарылган.

Гадәттә, халык хокукы турында аңа әмер биреп утыручылар күбрәк сөйли.

Бу кеше турында бары тик аның төрмәдә утырмаганлыгы гына билгеле. Ә менә ник утырмаган – монысы билгесез.

Бездә намуслы кешеләр, изгеләргә караганда, сирәгрәк очрый.

(сәясәт белгечләре мәҗлесендә язып алынды)





Янабыз, җәмәгать!

Бүгенге көндә "янгын сүндерүче кебек йоклый" дигән әйтем тарих тузаны белән капланды инде. Элек кенә ул янгыннарның күбесе тәүлекнең караңгы вакытына туры килгән, һәм төне буе ут белән көрәшкән янгынчылар көндезен йокы туйдыра торган булганнар. Электр һәм газ барлыкка килү белән аларның йокысы бөтенләй качты. Мәсәлән, яңа елның беренче атнасы эчендә генә республикада йөзгә якын янгын очрагы булган, һәм анда унлап кеше дөнья белән хушлашкан.

Ләкин, бәхеткә каршы, ул афәттән котылучылар җитәрлек. Менделеевск шәһәрендәге янгында 6 кеше котылган, аларның икесе бала. Ут сүндерүчеләр дә вакытында килеп җиткән. Бәхетсезлекнең чыганагын да тиз ачыклаганнар – ул бигүк аек булмаган хуҗа йоклап яткан диван булып чыккан. Ир кеше иске гыйбарәне оныткан: очкыннан да ялкын каба бит. Ә сүндерелмәгән сигареттан – бигрәк тә. Әйтергә кирәк, рәсми статистика буенча, янгыннарның уннан бере, ә янгында һәлак булу очракларының яртысы нәкъ пыскып яткан тәмәке төпчегеннән килеп чыга – ут чыганагы һәм аның сәбәпчесе янәшә булып чыга бит. Мондый очраклар шундый дәрәҗәдә ешайды ки, хәтта үзе сүнә торган сигаретлар җитештерү турында закон әзерләнә башлаган.

Яшел Үзән районы Васильево бистәсендә булган янгынның сәбәбе, зыян күрүчеләр әйтүенчә, мәчедә икән. Янып киткән фатир хуҗалары үзләре исән-сау котыла алган, ә менә чак исән калган мыекбайны кухнядан табып чыгарганнар. Кислород маскасы ярдәмендә һушына китереп, хуҗаларына тапшырганнар. Вакыйга моның белән генә тәмамланмаган – хуҗалар аны янгын чыгаруда гаепләгәннәр. Имеш, мәче, аларга ачу итеп, газ плитәсе артына йомышын үтәргә йөргән һәм анда электр чыбыгына зыян китергән. Утның башка урында чыгуына карамастан, усал хуҗалар йонлач дусларыннан баш тартканнар. Әле ярый, олы җанлы күршеләре бичараны, аның мәкерле максатына ышанмыйча, үзләренә алганнар...

Янгыннар статистикасында иҗтимагый транспорттагы янып китүләр аерым урын алып тора. Узган ел эчендә генә башкалабыз биш трамвайдан колак каккан – "эштә яну" дигән әйтем трамвайларга да кагыла башлаган, күрәсең. Сәүдә челтәрендә "кайнар тема"га багышланган бүләк-сувенир да барлыкккка килде. Янучы трамвай сурәтләнгән һәм "Ул синең чәеңне җылытыр" дип язылган кружкалар киң популярлык казанды...

"Утлы эстафета"ны автобуслар да эләктереп алды. Соңгы берничә ай эчендә ялкын телләре өч транспорт чарасының башына җитте. Бәхеткә, пассажирлар, мондый җылы мөнәсәбәттән башларын югалтмыйча, салоннан чыгып таюны хәерлерәк күрде. Ешаеп киткән очраклар белән шәһәр хакимияте дә кызыксына башлады. Югыйсә 12 ел элек пассажирларның иминлеген саклау йөзеннән хәвефле "ГАЗ"ель һәм "ПАЗ"иклардан баш тартканнар иде. Яңа автобус-трамвайлар сатып алып, чиновниклар казанлыларны шәхси машиналарыннан иҗтимагый транспортка күчеп утырырга өнди башлаган иде. Ә монда хәлләр...

Тикшерү эшләре барган арада, "кызыл әтәч" тынарга җыенмый һәм транспорт йөртүчеләрне чукый бирә. Яңа елның 5 гыйнвар иртәсендә Казанда тагын бер трамвай кабынып киткән. Янгынчыларның эше кимеми. Кем әйтмешли, аларда йокы кайгысы юк. Янабыз, җәмәгать, янабыз...

Людмила САФИУЛЛИНА



Вячеслав ШИЛОВ

Виктор ФЁДОРОВ



Александр ШУЛЬПИНОВ





• • •

Армиядән егетне күтәп алу, әлбәттә, батырлыкка тиң. Ә син менә яратып йөргән ярыңның хатынынnan аерылганын көтеп кара!..

• • •

– Стюардессаларга җайлы.
– Ни өчен?
– Аларның бөтен ирләре классларга бүленеп куела.

• • •

Ике хатын сөйләшә:
– Иреңнең кунарга кайтмаган вакыты булдымы?
– Бер тапкыр булды, өйләнешеп бер атна узгач.
– Сәбәбен ничек аңлатты соң?
– Аңлатканы юк әле, шуннан бирле кайтканы юк.

• • •

"Диваныңда ялкауланып ятма, нинди дә булса файдалы эш эшлә, дөньяң яхшырып китәр", – диләр. Өйне җыештырдым, саф һавага чыгып күнегүләр ясадым, өй кырыйларындагы чүп-чарны җыйдым һәм кар көрәдем. НДС шул килеш 20% калды, пенсия яшем кимемәде. Бәлки нәрсәнедер дөрес эшләмимдер?

• • •

– Аңламыйм, ни өчен балдак киеп йөрергә, бигрәк тә ир-атларга? Болай да бит инде күренеп тора, кемгә киемне әнисе сайлый, кемгә – хатыны.

• • •

– Нигә син Яңа елда аек идең?
– Хакимияткә санкция ясарга булдым. Ул минем пенсияне индексацияләми, ә мин аңа моның өчен аракыга акциз түләмим һәм тәмәкегә дә.

• • •

– Каян килә бу хаксызлык?
– Син нәрсә турында?
– Балта остасына килсәң – теләсә кайда пычкы чүбе, парикмахерда – чәч. Ә банкка керсәң – акча аунап ятканны күрмәссең. Җитмәсә, ручкалары да бәйләп куелган!

• • •

– Кызык, "кыен", "катлаулы" һәм "авыр" сүзләре синонимнармы?
– Юк! "Кыен" эчәргә дигән тәкъдимне кире кагу, "катлаулы" күләмен чамалый алмау, ә "авыр" – анысы инде иртәнге хәл...



Дамир МОРТАЗИН

Онытканым бармы соң?

Иртән уянуым булды, хатын:

– Эшкә барышлый чүпне түгәргә онытма!

Кайчан да булса онытканым бармы?..

Мәктәбенә җыенганда улым исемә төшерде:

– Әти, оныта күрмә, иртәгә классны ремонтлау өчен акча бирергә кирәк...

– Әйтмәсә дә була иде инде, онытаммы соң...

Метрога керешли динамиктан "Левитан" тавышы хәбәр салды:

– Гражданнар! Үзегезне һәм якын-тирәдәгеләрне саклау максатында битлекләрегезне, перчаткаларыгызны киегез!

– Белмиммени инде мин үземне сакларга кирәклеген.

Эшемдә шеф чакыртып алды:

– Исегезгә төшерәм – бүген отчет көне...

Әйтерсең лә минем отчет бирергә соңга калганым бар.

Коридорда урынбасары очрады:

– Онытмадыңмы? Бүген Хәлимовның юбилее – бүләк алырга акча җыябыз...

Юбилейларны беркайчан да уткәрми калмыйбыз инде. Гел истә.

Электрон почтага салым бүлегеннән хат килгән.

"Милеккә салым түләргә онытмагыз".

Әйтерсең лә кайчан да булса түләми калганым бар казна алдындагы бурычымны.

Ашханәдә төшке аш вакытында юан кассир хатын чиратка кычкыра:

– Социаль ара тоту турында оныттыгызмы әллә?! Роспотребнадзор тикшереп, ябуларын телисезмени ашханәне?!

Кычкырмаса да була бит инде ул хәтле, болай да гел берүзем йөрим, бик аралашмыйм кешеләр белән.

Эш көне ахырында, кроссвордлар чишеп алҗыган сәркатиб, катгый кисәтеп, эшкә килепкитеп йөрүебезне чутлый торган дәфтәренә билгеләнүне онытмавыбызны искә төшерде.

Нәрсәне-нәрсәне, ә монысын беребез дә онытканыбыз булмады.

Подъезд ишегенә белдерү ябыштырылган: "Гр. жильцы! Не забудьте вовремя сдать показания счетчиков!"

Счетчиклар турында беркайчан да онытканым юк!

Кичен телевизордан безгә гражданлык бурычы турында әйттеләр – сайлауга барып, лаеклыларга тавыш биреп кайтырга.

Лаексызларга тавышымны беркайчан да бирмәячәкмен!

Кичен канәгатьләнү һәм җан тынычлыгы белән йокыга талдым. Беләм, төнлә беркемгә дә кирәк булмаячакмын. Шунда касыкка хатын төртә башлады:

– Кадерлем, оныттыңмы әллә?

– Нәрсәне? – дип хафаланып куйдым.

– Ирле-хатынлы булып яшәү бурычы турында...



Вячеслав ШИЛОВ



Игорь КИЙКО



Николай ВОРОНЦОВ

Ринат АБЗАЛОВ

САГЫНЫП КАЙТТЫМ

(яшьлегем каласына)

Рәхмәт сиңа, күңелем түрендәге
Киң Себернең иске каласы –
Үз улыңдай сөеп кабул иттең
Читтән килгән татар баласын.

...Яңа җирдә яңа дуслар таптым,
Кызлары да чит-ят итмәде;
Тик тормышның салмак агышында
Миңа никтер нидер җитмәде...

Гаеп итмә, өзгәләде җанны
Тургай-сандугачлы бер авыл...
Сиңа таныш түгел сөйләмдә мин
Сагынып җырлар яздым, Барнаул!

...Зур күмәчнең сыр-эзләрен саклый
Аның кискән һәрбер телеме.
Гашыйк булсам да мин чал Себергә,
Кайттым сагынып туган телемне...

Михаил ЛАРИЧЕВ





Юрий КОНЬКИН

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рәшат Низами: Безне битлекләделәр дә – хәзер инде кешеләрнең чын йөзе югалып бара бугай.

Алмаз Хәмзин: Әмма хакимиятнең чын йөзе һаман саен ныграк ачыла бара...

Р. Н.: Әгәр РФ президентына бәя бирергә теләүчеләр табыла икән, алар аны артык агартырга да, артык каралтырга да тиеш түгелләр...

А. Х.: Аныкын бәяләп тормасаң да билгеле бит инде...

Р. Н.: Карьераң булмаса, "Кар ера" алмыйсың!

А. Н.: Максатың булмаса – "мәк сат" ып карыйсың...

Р. Н.: Күреп исем китте – бокста... атлеттан да "котлет" ясаучылар бар икән бит!

А. Х.: Ә сәясәттә тагын да көчлерәк ысул бар – гади халыктан хәерче ясау.

Р. Н.: Әгәр дә чалбарның кесәсе булмаса, ул сукыр бер тиенгә дә ярамас иде.

А. Х.: Төймәсе булмаса, диген...

Р. Н.: Себер карын күрмәгән африканнар Россия дигән илне аңлый алырлар микән?

А. Х.: Алар әле карсыз да аны аңламыйлар.

Р. Н.: Язмыш... дип аклану бигүк дөрес түгелдер, асылда Кеше үзенүзе "ясый"...

А. Х.: Бигүк ясап бетереп булмый шул әле, комачаулаучылар күп...

Р. Н.: Кайсыдыр районда бер әтәч алтын йомырка салган, дип сөйлиләр. Дөрес микән бу?

А. Х.: Минем дә ишеткән бар. Кайсыдыр главаның малае турында сүз барадыр...

Р. Н.: Дошманыңа аткан таш, бумеранг булып, үзеңә әйләнеп кайтасылар бер дә ерак йөрми.

А. Х.: Әйе шул. Миндә күп алар.

Р. Н.: Зур акылга ия кешегә, аның белән идарә итү өчен, тагын да зуррак акыл кирәк!

А. Х.: Бу фикереңөчен рәхмәт сиңа, Рәшат!

Р. Н.: Минемчә, маймыл кешедән килеп чыккан. Тәмәке тарту, аракы эчү кебек зарарлы гамәлләрдән читләшү өчен, алар йә урманга, йә Африкага качып беткәннәр...

А. Х.: Маймыл акыллары бар үзеңдә, Рәшат дус, ләкин бер дә үзең шунда качмыйсың...

Р. Н.: Сәрхушнең сүзләреннән дә исерек фәлсәфә аңкый.

А. Х.: Монысына җавап бирмәү кулайрак булыр... Үпкәләмә!..



• • •

Әнисе нәни кызына әкият сөйли. Кызы сорап куя:

– Әни, нигә бөтен әкиятләр дә: «Яшәгән ди...» дип башлана?

– Юк, кызым, – ди әнисе, – кайчагында алар «Кадерлем, бүген эш күп булды, шуңа тоткарландым...» дип башлана...

• • •

Нәниләргә Конституцияне балалар бакчасында ук укый башларга кирәк, ул бит бик матур әкият...

• • •

Бензин салу станциясендә улы – әтисенә:

– Әти, машина бензинны күп ашаса, ул үсә һәм автобуска әйләнәме?

Максим СМАГИН



Илдар НӘФИЕВ



Илдар НӘФИЕВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Виктор ФЁДОРОВ



Абау!

СОҢГЫ ЧИКТӘ

Татарстанның мәшгульлек һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова хәбәр итүенчә, республикада "ярлылык сызыгы" артында 289 мең кеше яши. Бу – бөтен гомуми халык санының 7,4 проценты. Шул ук вакытта боларның 70 проценты – балалы гаиләләр. Хәзерге вакытта мәшгульлек хезмәтендә 38 мең татарстанлы теркәлгән, ә узган ел аларның саны ун мең тирәсе иде. Шуны да истә тотарга кирәк, Татарстан нык-лы рәвештә илнең матди яктан иң уңышлы регионнары санына керә.

ГАУГАЛЫ БҮЛӘК

Яшел Үзәндә яшәүче 90 яшьлек Зәҗилә Мәүләвиеваны түгәрәк датасыннан бер ай алдан ук кисәтеп куялар: бу көнне өйдә утырыгыз, шәһәр хакимияте сезгә, хезмәт ветеранына, бүләкләр тапшырырга тели. Билгеләнгән вакытта хакимият вәкиле килеп, әбекәйгә тантаналы рәвештә... Владимир Путиннан котлау кәгазе тапшыра һәм хушлашып чыгып китә. Иҗтимагый челтәрләрдә купкан шау-шудан соң чиновниклар хаталарын төзәтергә була. Кәефе кырылган әби янына хакимият делегациясе килеп, аңа чәчәкләр, торт һәм бүләкләр тапшырып китә.

КЫЗЫК ЫСУЛ

Чаллыда яшәүче бер яшь хатынга декабрь өчен 32 мең сумлык счёт килә. Ул үзе зур булмаган ике бүлмәле фатирда ике кечкенә бала белән яши, коммуналь хезмәткә беркайчан да бурычлары булмый. Аптырашта калган һәм ачуы чыккан ханым моң-зарын иҗтимагый челтәрләрдә урнаштыра. Бу хәлгә Республика прокуроры Илдус Нәфыйков игътибар иткәннән соң, йорттагы фатирларның коммуналь торак буларак теркәлгәннәре ачыклана. Өч фатирлы блокта яшәүчеләрнең берсе ел буе счётчик мәгълүматларын тапшырмаган һәм шуңа күрә калганнарына түләүне норматив буенча исәпләгәннәр икән. Хатынга түләүне яңадан исәпләгәннәр. Нәтиҗәдә, счёт-фактурадагы саннар биш тапкырга кимегән.

КӨРӘШ НӘТИҖӘЛӘРЕ

2020 елда уздырылган сораштыру нәтиҗәләре буенча, коррупция алдынгылары сафында үзгәрешләр булган. Элек барысыннан да ешрак ришвәтне юл хәрәкәте инспекторлары, медицина хезмәткәрләре һәм педагоглар алган булса, хәзер педагоглар урынын полицейскийлар алган. Тагын бер нәрсә ачыкланган: ришвәтчелеккә каршы аяусыз көрәш алып барылуга карамастан, кирәк булганда һәр икенче кеше "төртергә" әзер икән.



Евгений ОБУХОВ

Йөрәктән...

Үз подъездында дан тоткан пенсионер Мотыйгуллин аптекага килеп керде. Бераз алга иелә төшеп, тәрәзәсеннән карады, ак халатлы чибәр яшь кызны төсмерләп алды.

«Эһемм! – дип елмаеп куйды ул. – Нинди гүзәл… Бер кырык ел элек мин моның белән!» Әзрәк уйланып торганнан соң төзәтеп куйды: «Илле ел элек…»

– Сезгә нәрсә, бабай? – дип сорады сабырлыгын җуя башлаган кыз.

– Миңа, кызым, теге… Ничек әле… Ни… Искә төшерә алмыйм…

– Хәтерне яхшырта торган дарумы әллә?

– Әйе, вәт-вәт! Хәтерне!

Кызый касса алдына тартма китереп куйды. Мотыйгуллинның йөзе балкыды:

– Вәт тишек баш! Искә төште – миңа бит ингаляция өчен пультифорт язып биргәннәр иде!

Чибәркәй компьютер төймәләренә баскалап алды да, экранга карап хәбәр итте:

– Бу бездә бар. Аласызмы?

– Ә инструкциясен карарга мөмкинме?

Кыз аңа кәгазь кисәге тоттырды. Мотыйгуллин чекрәеп карап торганнан соң тагын чибәркәйгә мөрәҗәгать итте:

– И-и, балакаем, кем генә баса торгандыр бу кәгазьләрне! Күздән берәр нәрсә табып бирмәссең микән?

«Балакай» тагын бер тартма тартып чыгарды һәм аның алдына ниндидер шешә китереп куйды. Мотыйгуллин уфтанып куйды:

– Бу кадәр әйбер алгач, арба кирәк булыр инде! Моны бит әле алып кайтасы да бар!

– Ә-ә, сезгә, бәлки, буыннардан да берәр нәрсә кирәктер? Менә мазь, – «Фил көче». Кирәкме?

– Нәрсә? – диде үз уйлары белән мавыккан Мотыйгуллин.

– Әһә, менә монысы колакка тамызырга… Барлыгы… Ике мең дә йөз ике сум.

– Ай! – дип йөрәгенә тотынды карт. – Ник килгәнем исемә төште… Йөрәк… Йөрәктән берәр нәрсә бир тизрәк! Йөрәктән!..





Александр АЛЁШИН

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА

Ел башының бер көне

Бәйрәм көннәре бик озакка сузылды. Ашау белән йоклаудан башка берни эшләнмәде. Телевизор карамакчы булсаң, анда карый торган нәрсә дә юк. Ел саен шул бер үк тапшырулар. Аны инде йокыңнан уятсалар да яттан сөйләп бирә аласың нәрсә күрсәткәннәрен.

Сабирҗан үзен нәкъ мәче шикелле хис итте. Хатыны табынны мул әзерли, шуңа күрә табыннан торып, кайсы бүлмәгә керсә, диван тора, шунда ава да йоклый. Йоклап торгач, тагын ашыйсы була.

Беркөнне түзмәде:

– Хатын, болай булмас, бераз урамга чыгып йөреп керим әле. Бөтенләй сулар хәлләр дә калмады бит инде бу ашау белән йоклаудан.

Шулай диде дә, киенергә тотынды. Абау, нәрсә бу?..

– Хатын, син бу киемнәрне юдыңмы әллә? Утырган бит. Киеп булмый!

– Тагын бер-ике көн шулай ятсаң, бөтенләй ишектән дә сыймассың әле, – диде хатыны елмаеп. – Мә, икенчесен ки, белгән кебек, синең сузылып беткән киемнәреңне ташламый торган идем.

Сабирҗан шуларны киеп, фатирыннан чыкты. Өске каттан җәяү төшсәң була иде дә, юк, ул лифт чакыртты.

Ишекләр ачылды. Анда аның шикелле юан, түгәрәкләнеп беткән тагын ике ир заты басып тора иде. Алты кеше сыярлык лифтка Сабирҗан кысыла-кысыла керде. Күршеләре бугай... Сәлам бирмәкче, тик анда сулыш алырлык та түгел – тыгыз. Кая инде сөйләшеп торырга.

"Ярар, чыккач сөйләшербез әле, сәламен дә шунда бирермен", – дип уйлап куйды ул. Барысы да шулай уйлый иде, күрәсең...

Менә төшеп тә җиттеләр. Иркен сулап, исәнләштеләр дә сүз башладылар:

– Бигрәк озакка сузылды инде бу бәйрәмнәр. Эшли торган эш тә юк бит бу шәһәр йортларында. Ашау белән эчүдән башка, – дип әйтеп куйды Сабирҗан.

– Ичмасам, авыл тирәсендә торсак, чыгып карын көрәп, йорт хайваннарын ашатып йөреп хәрәкәтләнү булыр иде, – дип кушылды күршесе.

– Әйе, менә кара син, күпме кар яуган, җыештыручысы да күренми. Ятадыр ялкауланып диванында. Ә кешегә йөрерлек юл да юк.

– Абзыйлар, – дип эндәште аларга үтеп баручы бер ханым. – Сез бәйрәмдә ашау белән йоклаудан башка берни белмисез бугай. Хатыннарыгыз сезнең кебек йокы симертмидер?..

– Юк ла инде, – дип җавап бирде Сабирҗан. – Минем хатын, әнә, кухнядан чыкмый. Тәмледән-тәмле ризыклар пешереп кенә тора, савыт-сабаларын юа, өй җыештыра.

– Шулай булгач, үзегез дә бераз хатыннарыгызга булышсагыз, хәрәкәтләнсәгез, үзегезгә дә файда булыр иде түгелме?

– Әйе, карагыз әле, дуслар, – диде Сабирҗан күршеләренә. – Чынлап та, әйдәгез әле бергәләшеп көрәкләр алыйк та ишегалдын чистартып чыгыйк. Кешеләргә дә, үзебезгә дә файда булыр.

Шулай килештеләр дә, торган йортларының ишегалдын кардан чистартырга тотындылар. Балаларга чана шуарга тау да ясап куйдылар. Күңелләрендә сөенеч иде. Менә бит, тырышсаң, шәһәр үзәгендә дә эш табарга була икән. Телевизор каршында гына ашап яту түгел.

Фатирларына күтәрелгәндә алар лифтка иркен сыйдылар.

Өйгә керү белән Сабирҗан тәрәзәдән тышка карады. Анда, чыр-чу килеп, алар ясаган таудан бала-чагалар чана шуалар иде. Ул тирән итеп иркен сулап куйды.

– Күптән шулай итәсе калган!





Валерий ТАРАСЕНКО рәсемнәре.

Абау!

КИРПЕЧ ПОЧТАСЫ

Кировта яшәүче бер ханым түрәләргә мөрәҗәгатен кирпеч белән җиткерергә булган. «Чүп чыгару хезмәте начар эшли, рәхмәт» дигән язу белән кирпеч Киров өлкәсенең хөкүмәт бинасының тәрәзәсенә очып кергән. Фаразланганча, моны капюшон һәм маска кигән яшь кыз эшләгән. Аны хәзер полиция эзли. Бу инде җирле хакимият адресына атылган өченче кирпеч булган. Беренчесендә автобуслар йөрүне көйләүне, икенчесендә һаваны пычрату проблемасын чишәргә таләп иткән булганнар.

ЯЛКАУ ЭШМӘКӘР

Юграның Белый Яр поселогының башлыгы Елена Никифорова бөтен көче белән муниципаль контракт буенча юл рәтләргә тиеш булган эшмәкәрнең теңкәсенә тигән. Түрә хәтта торак пунктта гадәттән тыш хәл режимы керткән. Эшмәкәр, зур штрафлар түләмәс өчен, килешенүдән баш тартырга мәҗбүр булган. Башлык, моның белән файдаланып, юлны рәтләү эшләрен бернинди конкурссыз башка подрядчикка тапшырган. Хәзер хакимият һәм эшмәкәрнең катлаулы мөнәсәбәтләрен прокуратура тикшерә.

АЛДАН КАЙГЫРТУ

Ростов-на-Дону шәһәренең яңа микрорайонында 32 светофор урнаштырганнар. Шәһәрнең юл хәрәкәтен оештыру бүлеге вәкиле Нарек Томразян аңлатуынча, күпме светофор булырга тиешлеге беркайда да билгеләнмәгән. Бу урында якын киләчәктә яңа йортлар төзеләчәк һәм аларны шуның өчен алдан урнаштырып куйганнар. Никадәр күбрәк, шулкадәр яхшырак бит. Ә әлегә җайга салырга берни дә юл хәрәкәте юк. Бу гаҗәеп светофор комплексы шәһәрнең чираттагы истәлекле урынына әверелгән.

КАССИР

Ростов-на-Дону шәһәренең инкассатор фирмасы хезмәткәре дүрт ел буе акча урлагап яткан. «Инкахран» компаниясендә эшләп, чын акчаларны «Приколлар банкы» купюраларына алыштырган. Шулай итеп бу ханым 10 миллион сум акча үзләштергән. Аңа карата җинаять эше кузгатылган.


Анатолий НЫРОВ


Максим СМАГИН



Виктор ФЁДОРОВ



ТИРЕС БЕЛӘН ТИКШЕРҮ

Дөмегеп киткере бу пандемия күпләрнең эшен катлауландырды. Пилорама директоры Солтан Габделхановичның да мәшәкатьләре күбәйде. "Өстәгеләр"нең күңелен күрер өчен, хезмәткәрләренә "СМС" таратты: "Үзендә авыру билгеләре сизгән һәркем өендә утырырга тиеш!" Аннан соң һәр кешенең өенә шалтыратып, бу "СМС"ны чынлап кабул итәргә кирәк булмавы, ә эшкә, хәленнең нинди булуына карамастан, элеккечә йөрергә кирәклеге турында хәбәр итеп чыкты...

Директор, ишек янында шкаф ясатып, анда дарулар, маскалар тутырды һәм йозак элеп куйды. Әмма хәлләр, гади салкын тию белән чикләнсә дә, начарайганнан-начарая барды. Яңа, прогрессив ысуллар кирәк иде. Температура үлчәү, дарулар сатып алуны теләсә кайсы җүләр булдыра ала, дип уйлады директор. Өстәвенә, бүгенге көн кадагы экономия бит! Һәм шунда ул коронавируска тест уйлап чыгарды – керү урынында тирес тутырган чиләк куярга. Керүчеләрне күзәтеп торырга сакчыларга күрсәтмә бирелде – әгәр хезмәткәр истән чыраен сыта икән, димәк, сәламәт, үтәргә ярый. Әгәр инде тыныч кына узса – кире борабыз.

Шулай итеп бер атна үтеп китә. Чиләк йөкләнгән вазыйфаны менә дигән итеп башкара. Сәер иснең сәбәбе белән кызыксынучыларга моны сантехника эшләре белән аңлаталар. Солтан Габделханович, үзенең ачышы белән горурланып, мыек астыннан елмаеп утыра бирә.


Ләкин тиздән көтелмәгән хәл була. Төнлә кемдер директор бүлмәсенә кереп, анда зур бер өем тирес бушатып чыга. Директор бик озак кешеләрне сораштырып йөрсә дә, берни дә ачыклый алмый.

Мирзаһит белән сөйләшкәндә болай дип җавап бирә:

– Солтан Габделханович, без атна буе сезнең тиресегезне иснәп йөрибез. Һәм үзебезне менә дигән тоябыз! Беркем дә авырмады һәм үлмәде. Киресенчә, эшчеләр үзләрендә яңа көч һәм дәрт тоя, ышаныч белән алга карый. Күрәсең, аларның берәрсе сезнең дә күңелегезне күтәрмәкче булгандыр. Көннәр буе шушы тынчу бүлмәдә интегеп утырасыз бит!

Икенче көнне үк тирес исе юкка чыга. Ә Солтан Габделханович шәһәргә китеп бара. Белгән кешеләр дарулар алырга китте, дип сөйлиләр...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Фәнзаман БАТТАЛ

АВЫЗЫН ЯПТЫ

Яхшы җырчылар юк, – диеп
Зарлана бөтен татар:
– Эшләр болай барса әгәр,
Сәнгатьнең хәле хәтәр.

– Көн дә бара экраннарда:
Бер үк көйгә – кырык җыр...
–Ни моңы юк, ни мәгънәсе –
Кем әйтмешли, «шыр да быр»...

...«Моңлы җырчылар кая?» дип,
Ник кабатлыйсыз һаман?
Моңлылар тыйнак заман бу,
Әрсезләр җиңгән заман.

Дөнья дигән бу куласа
Әрсезләрне коячак!
Коячак та, моңлыларны
Югарырак куячак!

ТАШЛАШУ

«Их, Язмыш, Язмыш!.. – диде ул,
Үткән гомерен уйлап. –
Гел аяк чалып йөрдең бит
Йөргәндә дөнья буйлап.

Ниятем чынга ашмады,
Ирешмәдем бәхеткә.
Син гаепле: менә хәзер
Юлым илтә ләхеткә...»

Шул чагында әйтте Язмыш:
– Сылтама миңа, бр-рат!!!
Гел киресен эшләдең син,
Тормадың миннән сорап!

«Уңга!» дисәм, сулга бардың,
«Алга!» дидем – чигендең.
Мин «бисмилла» әйткән чакта
Катлы-катлы сүгендең.

Ярый, сау бул, синең белән
Вакыт узды әрәмгә.

ТУКМАК ФАЙДАСЫ

Гадел дә, туры сүзле дә
Булыйм, диеп яшәдем...
Гел башыма кизәнделәр –
Күпме тукмак ашадым!

«Бетсен әйдә!», дигәннәрдер...
Үземнекен тукыдым.
Чүкеч астында төелгән
Кадак кебек ныгыдым!

Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 12, 1994



– Моңа тагын җәза биргәннәр!

Таһир ФӘИЗОВ, «Чаян» № 8, 1998



– Бер нәрсә юата – хәзер һәрвакыт аның кайда икәнен беләм!



• • •

– Һәр бөек ир артында бөек хатын тора.

– Моны инкарь итеп булмый! Алар кача-поса яши алалар...

• • •

– Эш бит сезнең гаиләгезнең бай булуында түгел, сезнең кызыгызны чыннан да яратам һәм аңа өйләнергә телим.

– Өчесенең кайсысына?

– Теләсә кайсысына...

• • •

Ике ир сөйләшә:

– Аерылышкач, хатын бөтен акчаны алып китте, тиенен дә калдырмады...

– Синең хәл ярыйсы икән әле. Ә минеке акчаны да алып бетерде, үзе дә китми калды...

• • •

– Кичә китап укыдым.

– Ниндине?

– Үземнекен. Хезмәт кенәгәсен. Сюжеты нинди, язмышы! Күздән яшь агарлык...

• • •

Ике түрә зиратта күптән түгел генә үлгән хезмәттәшләренең каберен эзлиләр. Аптырап бетәләр, ләкин таба алмыйлар. Кинәт берсе әйтеп куя:

– Карале, бәлки, ул каберен дә хатынына яздыргандыр?

• • •

Хатыны:

– Беләсеңме, мин нәрсә телим?

Ире:

– Әлбәттә, беләм – барысын да.

– Монысы – беренчедән...

• • •

Ике күршенең сөйләшүе:

– Күрәм, син һәр кичне машинаңнан бензинын агызып аласың да иртән кабат саласың...

– Шикләнәм, аның комсыз моторы бензинны төнлә дә ашый, ахрысы!

• • •

– Бабай, ә син әби белән ничек таныштың?

– Интернет аша.

– Ул вакытта интернет булмаган бит әле.

– Туктале, кайсы әбиеңне әйтәсең?

Илдар НӘФИЕВ



Александр КОСМЫЛИН





ЯҢА БОРЫЛЫШ – ИСКЕ ХАКЫЙКАТЬ

Кадерле "Чаян"! Халыкта "котырган этка җиде чакрым да урау түгел" дигән гыйбарә бар. Күрәсең, шушы халык әйтемен кулланып эш иткәннәрдер безнең хакимнәр, Колшәрип авылын чыккач Әлмәт юнәлешенә ясалган яңа борылышны төзегәндә. Безгә турыга бару юлын япканнар, тимер чыбыклы койма корганнар һәм, машинаны җиде километр читкәрәк куып, авылдан борылырга кушканнар. Моны безнең куркынычсызлыгыбыз өчен, дип аңлаттылар. Һәм шул игелекле теләкләре белән югалдылар. Шәһәр белән ике ара бермә-бер ерагайды – автомобиль йөртүчеләргә дә, ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәте өчен дә.

Ләкин шунысына игътибар итү мөһим: кайбер машиналар борылыш күрсәтелгән урынга барып җитмичә, койма беткән җирдән юл салдылар. Хәрәкәт, реконструкциягә хәтлегә караганда да, ныграк куркынычлы була башлады. Бәлки, кадерле "Чаян", түрәләр безнең зарны ишетер, һәм безгә таба борылыр, ә уңайсыз борылыш ягына түгел...

Колшәрип авылы халкы.

Әлмәт районы.

"КОЯШЛЫ" – КОЯШСЫЗ

Хөрмәтле редакция! "Кояшлы шәһәр" торак комплексына күчкәндә аның бөтен яктан да уйланып эшләнгән уңайлы инфраструктурасына сөенгән идек. Планда каралганча, монда ике мәктәп, даваханә, сәүдә үзәге, эштән соң ял итү шартлары тудырылачагына һәм үзенең паркы да төзеләчәгенә ышандык. Ләкин чынлыкта боларның хыялда калачагына төшендек. Торак комплексындагы мәктәптә, нормага караганда, хәзер күбрәк бала укый, даваханә дип төзелгән бинада – азык-төлек кибете, парклар, скверлар һәм төрле шартлар тудыра торган үзәкләр кәгазьдә генә исәпләнә.

Әле күптән түгел генә Бакый Урманче урамындагы вәгъдә ителгән паркта яңа торак комплексы – "Супер Кояшлы шәһәр" калкып чыкты. Монда бит инде төзелеш болай да бик тыгыз иде, хәзер хәтта Кояш та реклама буклетларындагы кебек кенә калыр микәнни? Вәгъдәләрне әйтеп торасы да юк...

"Кояшлы шәһәр"дә яшәүчеләр.

Казан



Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА

"ЧАЯН"НЫҢ ЯКЫН ДУСТЫ РИНАТ МӘННАНГА – 75! КОТЛЫЙБЫЗ!



Җәмәгать, 25 елдан февраль аенда миңа тәгәл 100 яшь була икән! Кызык бит, ә? Андый кызыклар тормышта күп әле. Менә, мәсәлән, башкалабыз уртасында бер бай кибет бар. Анда алтын, көмеш балдаклар, муенсалар саталар. Ә исеменә игътибар иткәнегез бармы? Нигә "Алмаз-Холдинг" дип язып куйганнар, Алмаз Хәмзинг түгел! Кызык бит. Югыйсә Алмаз Хәмзин күренекле язучы-сатирик, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Халык аны белә, ярата, аның концертларына рәхәтләнеп йөри. Кызык бит! Ә бер көнне барам автобуста. Карыйм урамга, бер өйдә язып куелган "Табейкин урамы" дип. Ә нигә әле Табиев түгел? Заманында Республикабызны күп еллар җитәкләгән кеше бит! Дөрес итеп язмыйлар дигәнем. Тукталышларда да шул ук хал. Тагын бер хата! Себер трактыннан автобуста барам, игълан итәләр: киләсе тукталыш "Архив" дип. Нинди архив! Ике хәрефне төшереп калдырганнар. Минем чын фамилиям Архипов бит, архив түгел! Кызык бит. Җитешсезлекләр күренеп тора шул. Ә менә күренекле шагыйрь, прозаик, драматург күп кенә премияләр лауреаты Ләбиб Леронны бик жәллап куйдым әле. Ерак түгел тора торган җиремдә күптән түгел зур гына кибет ачтылар. Исеме Ләбиб Лерон урынына "Леруа Мерлен" дип язып куйганнар. Нигә инде менә шулай кешедән көләргә! Матур гына исемен бозып язарга. Менә тагын бер мисал сезгә. Казанда "Каштанов урамы" бар икән. Ә нигә язып куймаганнар исемен – Нәкыйп дип. Ул – халыкка танылган язучы, Пётр I исемендәге фән һәм сәнгать академиясенең академигы, өстәвенә, әле табиб та! Ә менә күренекле язучыбыз Марсель Галиев өчен чын күңелемнән сөендем. Аның да урамы бар икән, исән-сау булуына карамастан! Ул бик лаеклы бу ихтирамлыкка. Аның "Рух" исемле китабы гына ни тора! Авырлыгы ким дигәндә 2-3 килограмм булыр! Талантлы шагыйребез Тәүфыйк Камалиевның да урамы бар икән. Бу бик әйбәт күренеш. Исәннәрдән дигәндә, бик сөендем безнең яраткан "Ак барс" хоккейчылары өчен. Батыршин белән Яруллин әле яшь булсалар да, ә урамнары бар икән. Маладислар, моңа ни әйтәсең?! Тагын бер сөенечем турында әйтми кала алмыйм. "Чаян"ны күп еллар җитәкләгән баш мөхәррир Зәкиевкә дә язмыш әйбәт кенә елмайган икән. Бер көнне барам шул бер кызыл автобуста һәм "Киләсе тукталыш "Зәкиев урамы" дип әйтмәсеннәрме! Әй, сөендем дә аның өчен. Түрәләр тәки күреп алганнар бит аның эшен һәм тиешенчә билгеләгәннәр дә! Соң булса да уң булсын диләр бит бу очракта. Бик дөрес сүзләр!

Мин дә бик калышмаска булдым әле күренекле кешеләрдән. Үземнең юбилеема берничә юмористик шигырьләремне яраткан "Чаян" журналыма җибәрергә булдым. Шуларны укып елмаеп алсагыз, миңа шул җитә, артыгы кирәкми.

ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ

Бераз гына борынгы,
Бераз гына борынлы.
Үзтотышы уңайлы,
Иҗатында – Тукайлы!

РИФАТ СӘЛАХКА

Яздың да яздың диптих син,
Булдың искиткеч армас.
Алга да атларга кирәк –
Бер кочак триптих та яз!

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА

*Ринат Мәннан, кызып китеп,
Равил Файзуллинга да
бер мактау чәпегән:*

Карап торсаң, юан түгел,
Түгел озын да.
Әмма озын һәм юаннар
Аны зурлап – хөрмәт итеп
Башларын аска ияләр
Аның алдында.

ФӘРИТ ЯХИНГА

*Фәрит Яхинны
60 яшьлек
юбилее белән
котлап язган
эпиграммасын да өстик:*

Вакыт бушка
Ага димик.
Фәрит булды
Академик.

РАШАТ НИЗАМИЕВКА

Олыгая барган саен,
Шигырьләрең кыскара.
Бу күренеш бик өметле –
Димәк, дускай остара!

ЗИННУР МАНСУРОВКА

Берлектә өч йөздән артык
Исәпләнә язучы,
Син бердәнбер – Тукай белән
Әңгәмәләр коручы!

МАНСУР ВӘЛИ-БАРҖАЛЫГА

Җылы бар, димәк, такмаган
Исеменә суык дип.
Моңа бар да нык шатланды –
Җылыда яши әдип!

ЛӘБИБ ЛЕРОНГА

Син кайда идең,
Кайларда йөрдең.
Кайда түрәләр
Булдылар икән?
Син җитәкләгән
"Безнең мирас"ны
Хәзер алар да
Укыйлар икән.
Бик рәхәтләнеп,
Бик ләззәтләнеп
Актаралар ди
Аның һәр санын.
Күпме мәгълүмат,
Күпме яңалык...
Сөендердең бит
Татар инсанын!



Сергей ЕРМИЛОВ



Шөреп кадере

...Пистолеттан атабыз. Балачакта хыялга да кермәгән Макаров пистолетыннан бит! Үзең патронын корасың, затворын тартып, кулыңны туп-туры куеп, мишеньгә төбәп, курогын тартасың...

Кызык, рәхәт булгандыр дип әйтә алмыйм, чөнки сугышлы уйнап йөргән балачагыбыз бик еракта калган инде. Хәзер безгә егерме икешәр, минем ише армия сафларында хезмәт итеп кайтканнарга егерме алты яшь. Без дигәнем – Казан дәүләт университеты каршында хәрби кафедра курсантлары. Анда укырга кергән студент үзе сайлаган һөнәре белән бергә хәрби белгечлек тә ала, без, мәсәлән, пехота командирлары булып чыгабыз. Безгә "Запастагы офицер" дигән таныклык тапшырыла һәм хәрби исәпкә куела. Вузда белем алу ир-егетләр өчен шушы ике айлык җәйге лагерьларда полигонда сынаулар узу, имтиханнар тапшыру белән тәгәлләнә.

Пистолеттан атабыз, дидем. Мин – взвод командиры. Минем белән бер сафта сабакташ дусларым. Полигонга иртәнге сәгать өчтән торып килгән идек. Иртәнге ашка кадәр бу бурычны да уңышлы гына үтәп кайту иде бурычыбыз. Шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, кемнеңдер саксызлык күсәтүе аркасында, пистолетның бер шөребе (предохранителе) төшеп югалган гына бит. Пистолет сафтан чыккан. Кул куеп алынган коралны кире тапшырасы бар. "Отбой" дигән команда яңгырады. Тотындык теге шөрепне эзләргә. Бирәдә дә, тапталган булса да, бөтен җирне үлән баскан, табып кара шул үлән арасыннан бармак очы кадәр тимер кисәген. Бер сәгать, ике сәгать вакыт үтте, юк, таба алмадык. Инде иртәнге аш вакыты да узды. Таң алдыннан горизонт сызыгында күренгән кояш та, баш түбәсеннән торып безгә булышкандай итә. Нәтиҗә юк. Җаваплы офицер-подполковник, безне сафка төзеп, тапкан курсантка өч тәүлек откуск бирергә ышандырды. Без янә таралышып үләннәр арасына текәләбез. Шөреп юк та юк. "Өч тәүлек" дигән сүз "бишкә", тагын берәр сәгатьтән "ун тәүлек"кә җитә. Ун тәүлек ял! Ул кемгә эләгер икән?! Ял! Нинди матур, кадерле, күңелгә якын сүз ул. Миңа, мәсәлән, Байконурда хезмәт иткән елларда, ул ялның рәхәтлеген татырга, тәмен белергә, туган якларыма кайтып әти-әнием, туганнарым янында торып килергә насыйп булды. Ун гына көнгә! Әмма шушы кыска гына вакыт күңелдә гомер буе искә алырлык хатирәләр калдырды. Рәхмәт язмышка. Бүген дә без шул халәттә. Һәркайсыбыз теге шөрепне табып, ун көн ял итеп килү турында хыяллана. Мин дә кайтып, бабайга ун көн буе печән чабып килү уе белән теге шөрепне эзлим. Ә ул бәхет география факультетында белем алган чуаш егетенә тәтеде. Һәм ул, төшке ашны да ашамыйча, Чабаксарына кайтып та китте...

Ял, дидек, ялның тәме, дидек... Ә ул ял лаеклы ялга чыккач (мин 60 яшьтән пенсиягә чыктым) бигрәк тә татлы була икән шул.

Менә без Ясминә исемле өч яшьлек дүртенче оныгым белән Имәнлек урманында йөрибез. Күз ачып йомган арада кырык ел үткән дә киткән. Шәһәр тирәсендәге үсеш-үзгәрешне искә алмаганда, урман эчендә әллә ни үзгәреш булмаган да кебек. Лаеш ягындагы полигоннан кайтып йөргән урман юлы буйлап атлыйбыз. Ә оныгымның үз кызыксынуы, дөньяны танып-белү чорыг дииме соң. Һәрбер җиргә тәртелеп-тукталып: "Бу нәрсә?", "Ә бу нәрсә?" дип, сорау арты сорау яудыра, җавап кына биреп өлгер. Аннары без имән төпчеге өстендә әрле-бирле йөгергән кырмысканы күзәтәбез.

– Кырмыска баласы адашкан, әтисен эзли, – дим.

– Юк, – дип каршы төшә сабый. – Ул уйный, әнисе кибеткә кәнфит алырга киткән...

Безнең уйларны урманның аргы башындагы полигон ягыннан ишетелгән мылтык тавышлары бүлә.

– Салют! – дип куя оныгым. Унҗиденче каттан карап күзәткәнгә, һәр шартлаган тавыш сабыйга бәйрәм тантанасы булып күренә торгандыр шул, "салют"тыр.

Ә чынлыкта исә кайдадыр хәзер дә өйрәнүләр бара. Бу тавышлар шуңа ишарә. Кайдадыр "гипер" ракеталар сынала. Һәр шөреп, һәрбер тимер кисәге кадерле бездә. Алар янәшәсендә әвәрә килгән солдатларга, кешеләргә дә шундый ук игътибар бирелә микән?! Шөреп кадерен, кеше кадере белән чагыштырып карау лөгатькә бигүк туры килеп бетми торгандыр да, әмма...

Сүз дә юк, кадрлар да кирәк, корал да... Ватаныбызны саклау безнең һәрберебезнең изге бурычы! Без моны яхшы аңлыйбыз. Тик менә... минем взводның (взводта 28 солдат) ун курсанты, башкача итеп әйтсәк, ун сабакташ дустым алтмыш яшенә җиткәнче үк бакыйлыкка күчте. Дөрес, сәбәпләре төрле булгандыр, кызганыч, әлбәттә, аларга оныкларын җитәкләп бу сукмактан йөрергә насыйп булмаган...

("Азатлык"та китерелгән Росстат мәгълүматларына караганда, 2020 елның гыйнварының ноябренә кадәр Татарстанда 48453 кеше үлгән. Бу – узган елның шул ук вакыт аралыгына караганда, 9202 кешегә күбрәк – **М. С.**)

Бу мисал инде хәл ителгән мәсьәләгә янә бер кабат күз салырга мәҗбүр итә. Пенсиягә чыгу яшен ашыгыбрак арттырып куймадык микән, дим. Өлкән яшьтәгеләргә икенче яктан коронавирус та һөҗүм ясый бит әле. Конституциягә үзгәрешләр кертә алдык. Бу проблемага да бер әйләнеп кайтуыбызга ышанам. Аның әллә нинди җайлы юллары да табылмый калмас иде. Ул чагында без – өлкәннәр дә шартлау тавышларын "салют"тыр дип кенә уйлар идек.

...Без Имәнлек урманыннан чыгып киләбез. Әйткәнемчә, урманның теге башыннан тоныкына ату тавышлары ишетелгәләп ала. Анда булачак яшь командирлар пистолеттан аталар бугай...

Мидхәт САДЫЙКОВ



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 2 (1903) февраль 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде. Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылса алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.02.2021 ел.
Тираж – 3323 Заказ Е-215

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

Композитор ... Әхмәдиев; Җырчы Усман ... "Сутый"; Сибгат ...; ... де Бальзак; Антонов Самолёты; Винсент ... Гог; Дым сөючән тамырсыз үсемлек; Биеклек; Чүлдәге инеш ... гамбәр; Көньякта бард; Кыр-басу белгече; Җырчы Илфак ...; Балерина ... Хәкимова; "... каен"; Халыкара "Кызыл ..." комитеты; Архитектор Руфин Г...; Ил белән берүзе идарә итүче; "Тагын хуш ... бөрки сиреньнәр"; Нота "Бик салкын ... бик эссе түгел"; Ак ... банк; Немец физигы; (-1) Зур елан һәм озын шарф; Җитез, шук; Сара ... Ватылса – утын; "Мин ... чәчәкләрне эзлим"; ... (-1) киеме; Нота; Нәсел; Нота "Бик сагындым ... буйларын"; "... су юлын таба"; Моңлы (-1)...; "Суда ... йөзәдер"; Чыршы ботагы; Колак табибы; "Күп гасырлар шаулый бер ..."; "Саумы, ... саумы, иртә"

10, 6, 16, 8, 14, 15, 3, 12, 2, 9, 11, 4, 13, 5, 1, 7

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. "Социаль лифт" карьера баскычыннан нәрсәсе белән аерыла?

2. Көн саен театр сәхнәсенә чыга торган кешене ничек исемләргә?

3. Кем ул мерчендайзер?

4. Кешеләр арасындагы төп мөнәсәбәт?

5. Дарулар кемгә күбрәк булыша?

6. Гашыйк булганда кешенең аркасы нигә чымырдап куя?

7. "Егет әйтә – егет эшли" логик бәйләнештә нәрсә җитеп бетми?

ҖАВАПЛАР

1. Карьера баскычына әкренләп күтәреләсең, һәм гомер буе күп көч түгәсең. Социаль лифтта кайсы кнопкага басасын белсәң, шул җитә – очып кунасың. 2. Җыештыручы. 3. Гипермаркет киштәләрендәге товарларның урыннарын отып калмасыннар өчен, алыштырып йөрүче кеше. 4. Ышаныч язуы. 5. Аларны саткан кешеләргә. 6. Ул төпле мәгънәнең тәннән чыгып китүе. 7. "Егет уйлый".

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 2021 елның 1 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«ӘНИЕМ МИЛӘШЕ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

И. ВӘЛИЕВ (Ютазы р-ны, Яңа Караҗирек ав.),
Н. НИКИТИНА (Чистай р-ны, Чуаш Ялтаны ав.),
Ф. ГЫЙБАДУЛЛИНА (Балтач р-ны, Сосна ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Чуаш Ялтанынnan

Нина НИКИТИНА!





Юрий КОНЬКИН



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр АЛЁШИН



Александр ШУЛЬПИНОВ

